| | |
|---|---|
| **Республика Татарстан<br>Исполнительный комитет<br>Александровского сельского<br>поселения Александровского<br>муниципального района** | **Татарстан Республикасы<br>Сарман муниципаль<br>районының<br>Александровка авыл<br>җирлеге башкарма<br>комитеты** |

| | | |
|---|---|---|
| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**<br>25 ноябрь 2022 ел | с.Александровка | **КАРАР**<br>№ 11 |

Александровка авыл җирлеге Башкарма комитетының«Белешмә (өземтә) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административрегламентын раслау турында» 2022 елның 21 апрелендәге 4 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 15 августындагы 1415 номерлы Россия Федерациясе карарының 1 пунктының а пунктчасы нигезендә Сарман муниципаль районы Александровка авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Александровка авыл җирлеге Башкарма комитетының «Белешмә (өземтә) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2022 елның 21 апрелендәге 4 номерлы карарына түбәндәге үзгәреш кертергә:

1) 3.3.2.1 пунктның 11 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Формат-логик тикшерү Бердәм портал тарафыннан мөрәҗәгать итүче тарафыннан һәр запросның электрон формасын тутыру процессында орган (оешма) билгеләгән таләпләр нигезендә автоматик рәвештә гамәлгә ашырыла. Бердәм портал белән запросның дөрес тутырылмаган электрон формасындагы кырын ачыклаганда мөрәҗәгать итүче ачыкланган хатаның характеры һәм аны бетерү тәртибе турында электрон формада мәгълүмати хәбәр аша хәбәр ителә.».

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» (pravo.tatarstan.ru) һәм «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендә (sarmanovo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен үзем контрольдә тотам.

Александровка авыл җирлеге
Башкарма комитеты җитәкчесе — И.Ф.Вафин